ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.09.2025 г.Лениногорск № 826

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән расланган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРДЕ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 09 августындагы 728 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 09 августындагы 728 номерлы карары белән расланган Рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 09 августындагы 728 номерлы карары белән расланган Территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең яңа редакциядә административ регламенты;

Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 16 августындагы 747 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Татарстан Республикасының «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 сентябрендәге 879/1 номерлы карары белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне, документларны, материалларны күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының яңа редакциядә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 879/1 карары белән расланган «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүнең мәгълүмати системасындагы белешмәләрне, документларны, материалларны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 28 апрелендәге 405 номерлы карары;

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 30 сентябрендәге 879/1 номерлы карары белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне, документларны, материалларны күрсәтү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 14 декабрендәге 1165 номерлы карары.

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче М.Н.Гирфанов

Галимова Л.М.
5-44-72